| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “12” 10.2015 № 396

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге № 212-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.11.2010 № 906 карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының
2015 елның 12 октябрендәге
396 номерлы боерыгы белән
расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ КАРШЫНДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ТУРЫНДАГЫ НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба - Иҗтимагый совет) транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында гражданнар хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән коммерциячел булмаган оешмаларның хокукларын яклауны гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карау буенча Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба - Министрлык) каршындагы киңәшү органы булып тора.

1.2. Иҗтимагый совет составы һәм саны Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Үз эшчәнлегендә Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) таяна.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү характерында була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

1.6. Иҗтимагый совет эше Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә ихтыярыйлыкка, ачыклык һәм партнерлык принципларына катгый рәвештә корыла.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен граждан җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. Иҗтимагый совет эшчәнлеге максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенен төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда, гражданнар ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнар хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән коммерциячел

булмаган оешмаларның хокукларын яклаудан;

иҗтимагый, профессиональ һәм иҗади берләшмәләрнең вәкилләрен Министрлык эшчәнлегенең тиешле өлкәсенә кагылган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешен билгеләгәндә җәлеп итү;

Министрлык эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы һәм ачыклыгы принцибын тормышка ашырудан;

Министрлык күрсәтә торган хезмәтләр сыйфатын җәмәмгатьчелек тикшереп торуын көчәйтүдән, Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә җирле дәүләт тикшереп торуын тормышка ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм профессионализм принципларын үстерүдән.

2.2. Иҗтимагый совет бурычлары түбәндәгеләр:

транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Министрлык эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру;

законнарда каралган очракларда Министрлык тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектлары буенча алдан фикер алышу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү дәрәҗәсен арттыру.

2.3. Иҗтимагый совет максатлары һәм бурычлары аның эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый. социаль һәм сәяси ситуацияне исәпкә алып, үзгәртелергә һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет рәисе, рәисе урынбасары, секретаре һәм әгъзалары составында гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, коммерциячел булмаган оешмалар, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тәкъдимнәре нигезендә төзелә. Иҗтимагый советның шәхси составы Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры (алга таба – министр) тарафыннан раслана.

3.2. Иҗтимагый совет 6 кеше составында ихтыярыйлык нигезендә төзелә.

3.3. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм бүтән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре булган гражданнар да керә ала. Бу чакта аларнын профессиональ сыйфатлары исәпкә алына, шул исәптән тиешле белеме, транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен кирәкле эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән затлар Иҗтимагый совет әгъзаларынын яртысын тәшкил итүче санда кертелә.

3.4. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, Россия

Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфалар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук суд карары нигезендә хокукка сәләтсез дип танылган затлар, юкка чыгарылмаган һәм бетерелмәгән хөкем ителеше булган затлар, ике гражданлыгы булган затлар, шулай ук "Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 4 апрелендәге № 32-ФЗ Федераль законны буенча Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының әгъзалары була алмаган бүтән затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәисе урынбасары, әгәр алар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыграгы тавыш бирсә. Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан сайлана. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәисе урынбасарын сайлау турындагы карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен һәм рәисе урынбасарын Вазыйфасыннан азат итү турындагы мәсьәлә министр мөрәҗәгате буенча, шулай ук аларның шәхси гаризасы яисә Иҗтимагый совет әгъзаларының биштән бере тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала.

Әгәр карар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, карар кабул ителгән дип санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракта туктатыла:

Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза биргән;

сәламәтлеге торышына бәйле рәвештә Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаган, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән үзе читләшкән яисә башка сәбәпләр булган;

аңа карата гаепләү турында чыгарылган суд карары закон көченә кергән;

закон көченә кергән суд карары нигезендә аны хокукка сәләтсез яисә хәбәрсез килми калган дип таныган;

аның әхлакый нормаларны дорфа бозуы - утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавышы белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Россия Федерациясе гражданлыгын туктаткан;

чит дәүләт гражданлыгын (ватандашлыгын) алган;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә даими рәвештә (оч мәртәбәдән дә артык) мәгълүм сәбәпсез катнашмаган;

Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасары кушканнарны мәгълүм сәбәп буенча даими рәвештә (ике мәртәбәдән дә артык) үтәмәгән;

әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән вазыйфага керешкән очракта.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзалыгын тукгату Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы йә Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасары тәкъдиме нигезендә кабул ителә торган министр карары нигезендә гамәлгә ашырыла, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында каралган хәлләр ачылган очракта.

Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге торышына, аңа карата гаепләү турында чыгарылган суд карары закон коченә кергән, Россия Федерациясе гражданлыгын туктатуга бәйле рәвештә эшчәнлеге башкара алмаган очракта,

Иҗтимагый совет әгъзасы шушы фактлар турында Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәисе урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча министр карары нигезендә түбәндәге очракларда туктатып торыла:

Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә аңа карата җинаять кылуда гаепләү белдерелгән;

административ кулга алу рәвешендә ана карата административ җәза билгеләнгән;

дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатлыгына кандидат вазыйфасына кандидат, жирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яисә вәкаләтле заты сыйфатында аны теркәгән, шулай ук ул Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатив торкем составына кергән очракта.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Министрлык инициативасы буенча уздырыла торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “түгәрәк өстәлләрдә” һәм башкаларда), катнашырга, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләре, шәхси күрсәткечләр турындагы белешмәләре булган мәгълүматтан һәм алуы чикләнелгән мәгълүматтан файдалануга бәйле рәвештә федераль законнар нигезендә керүе чикләнгән чаралардан гайре;

инициатив гәртиптә аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмат-апалитик материаллар әзерләргә һәм Иҗтимагый советка җибәрергә;

Иҗтимагый совет эше планына һәм аның утырышларын уздыру тәртибенә Иҗтимагый совет рәисе аша тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибе мәсьәләләрен карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышына чакырылучы затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлары:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәргә;

әлеге Нигезләмә белән каралган Иҗтимагый совет эше тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында үзе катнашырга;

Иҗтимагый советка йөкләнгән бурычларны Иҗтимагый совет тарафыннан хәл итү өчен төзелә торган эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, бүтән эш органнары эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Министрлык тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кимендә кварталга бер мәртәбә уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм Министрлык тарафыннан эшләнә торган бүтән документлар исемлеге белән каралган норматив хокукый актларның Министрлык тарафыннан эшләнгән, “Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган, башкарма хакимиятнең шушы органнары каршындагы иҗтимагый советлар тарафыннан алдан каралмыйча кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм бүтән документлар составын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.03 2013 № 214 карары белән расланган Министрлык каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан карамыйча кабул ителүләре мөмкин булмаган проектларына һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына билгеләнгән тәртиптә теркәүгә җибәрелә торган Министрлык норматив хокукый актларына Иҗтимагый совет тарафыннан бәяләмәләр бирү максатларында Министрлык инициативасы буенча да уздырыла.

5.4. Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, алар тулы вәкаләтле дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасы утырышта үзе катнаша алмаганда көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын Һәм уз фикерен язма рәвештә, факсимиль яисә электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыра ала, бу хакта ул Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәисе урынбасарына йә Иҗтимагый советның җаваплы секретарена алдан хәбәр итә. Утырышта катнашучылар санына Иҗтимагый советның үз тавышын башка Иҗтимагый совет әгъзасына ышанып тапшырган әгъзалары да өстәлә.

Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын (норматив хокукый актларын) карау алар Министрлык тарафыннан Иҗтимагый советка җибәрелгән көннән ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Бу чакта алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирү уздыру Иҗтимагый совет әгъзаларының барысыннан да сорашып чыгу рәвешендә читтән торып та гамәлгә ашырылырга мөмкин, нәтиҗәләр Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертелергә тиеш, рәис булмаганда - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан. Мондый тавыш бирү документтларны почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон чара аша яисә тапшырыла һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең тәнгәллеген һәм аларның документаль расланышын тәэмин итүче бүтән элемтә аша да алмашу юлы белән уздырылырга мөмкин. Читтән торып тавыш бирү очрагында, тәкъдим ителүче көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирелергә тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт), утырыш уздырырга җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, барлык әгъзаларына җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары кирәк булганда Министрлыктан карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе уздыра, ул булмаган очракта - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары.

5.6. Иҗтимагый советның үзенә йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләр нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим характерында була һәм Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә йә Иҗтимагый совет карары буенча бүтән ысул белән кызыксынучы затларга җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтындагы “Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет” бүлегендә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эше планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына тапшыра;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышы көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет рекомендацияләренә, Иҗтимагый совет беркетмәләренә һәм бүтән документларына имза сала;

Иҗтимагый совет утырышларын уздыру вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый советка йөкләнгән максатлар һәм бурычлар нигезендә Иҗтимагый совет эшчәнлеге кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән гарызнамәләргә, рекомендацияләргә, тәкъдимнәргә, җавапларга, аңлатуларга һәм мөрәҗәгатьләргә имза сала;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле бүтән вазыйфаларны гамәлгә ашыра.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмаганда соңгысының вазыйфаларын үти;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисе раславына тапшыра;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеге тәэмин итү өчен кирәкле бүтән вазыйфаларны гамәлгә ашыра.

5.10. Иҗтимагый совет җаваплы секретаре:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышын уздыру вакыты һәм урыны, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән Министрлык арасындагы хезмәттәшлекне оештыруны тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп тора;

Иҗтимагый совет утырышлары көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңлау һәм фикер алышу мәсьәләләрен әзерләү өчен эш, эксперт төркемнәренә һәм бүтән эш органнарына берләшергә, материалларны әзерләү өчен Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп, Иҗтимагый совет составына кермәүче белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына башкарма хакимияте органнары, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында булырга мөмкин.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар, Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына ун календарь көннән дә сонга калмыйча, Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.